ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Китапханәләр һәм китапханә эше турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 11 июлендә
кабул ителде

## 1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре, «Китапханә эше турында» 1994 елның 29 декабрендәге 78-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон), башка федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасында китапханә эше өлкәсендә Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертелгән аерым мәсьәләләрне җайга сала.

## 2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

## 3 статья. **Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) китапханә эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне законнар белән җайга салу;

2) китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасы законнарын үтәүне һәм аларның үтәлешен тикшереп тору;

3) Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында каралган башка вәкаләтләрне башкару.

2. Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1) китапханә эше өлкәсендә чаралар күздә тотыла торган Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләү, раслау һәм гамәлгә ашыру;

2) Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләрен оештыру, үзгәртеп кору һәм бетерү;

3) Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре фондларын туплауны һәм аларның сакланышын финанс белән тәэмин итү;

4) Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләрендә гражданнарның китапханә хезмәтеннән файдалану хокукын гамәлгә ашыруны тәэмин итү;

5) Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләреннән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар тудыру;

6) бердәм китапханә статистикасын оештыру, аның дөреслеген, үз вакытында алып барылуын һәм ачыклыгын тәэмин итү;

7) китапханә эше өлкәсендә фәнни тикшеренүләргә, методик тәэмин итүгә булышу;

8) китапханә эше өлкәсендә законнарда каралган башка вәкаләтләрне башкару.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстаи Республикасы вәкаләтләре чикләрендә китапханә өчен кадрлар әзерләү өлкәсендә төп һөнәри белем бирү программаларын һәм өстәмә һөнәри программаларны гамәлгә ашыра торган Татарстан Республикасы белем бирү оешмаларын төзергә һәм финансларга хокуклы.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының әлеге статьяның 2 һәм 3 өлешләрендә күрсәтелгән вәкаләтләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мөстәкыйль яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы тарафыннан башкарыла.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе законнары нигезендә муниципаль китапханәләргә, шул исәптән китапханә фондларын туплау өлешендә, ярдәм итәргә мөмкин.

4 статья. **Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

Китапханә эше өлкәсендә Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары вәкаләтләре Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

5 статья. **Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерү**

1. Татарстан Республикасы китапханә эшен үстерүдә Татарстан Республикасы территориясендә китапханәләр тарафыннан җыела һәм куллануга бирелә торган мәгълүматтан һәм мәдәни кыйммәтләрдән гомуми файдалана алу өчен шартлар тудыру принцибы нигезендә катнаша.

2. Татарстан Республикасы әлеге Законда каралган хокукларның гаранты булып тора һәм, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш, китапханәләрнең һөнәри эшчәнлегенә катышмый.

3. Татарстан Республикасында китапханә эшен үстерүнең өстенлекле юнәлешләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) һәркем файдалана алырлык китапханәләр челтәрен, шулай ук китапханәләрдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтүнең стационардан тыш төрләрен үстерү;

2) китапханә фондларын төрле саклагычлардагы заманча мәгълүмат чыганаклары белән системалы рәвештә туплауны тәэмин итү;

3) китапханәләрне квалификацияле кадрлар белән тәэмин итү, китапханә хезмәткәрләрен әзерләү һәм аларның квалификациясен күтәрү;

4) китапханә эшен мәгълүматлаштыру, китапханә эше өлкәсендә кулланыла торган технологияләрне программа белән һәм лингвистик тәэмин итү.

4. Китапханә эшен үстерүнең бурычлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) гражданнарның мәдәни һәм интеллектуаль дәрәҗәсен арттыру, аларны укырга җәлеп итү өчен шартлар тудыруга ярдәм итә торган мәгълүмат, мәдәният һәм аң-белем тарату үзәкләре буларак, Татарстан Республикасы китапханәләренең эшчәнлеген камилләштерү;

2) һәркем файдалана алырлык китапханәләр фондларын яңа технологияләр базасында булдыру, саклау һәм файдалану;

3) китапханәләрдән файдаланучыларга хезмәт күрсәтү дәрәҗәсен уңайлы мохит тудыру, шул исәптән мәгълүматлаштыру аша арттыру.

5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнары бюджеттан финансланучы гамәлдәге китапханәләрнең матди-техник тәэмин ителешен начарайтуга, аларны хезмәтне саклау, китапханә фондларын саклау һәм китапханә хезмәте күрсәтү таләпләренә туры килми торган биналарга күчерүгә китергән карарлар кабул итәргә һәм гамәлләр кылырга тиеш түгел.

6 статья. **Китапханәләрдән файдаланучыларның хокуклары һәм җаваплылыгы**

1. Һәрбер граждан, җенесенә, яшенә, милләтенә, белеменә, социаль хәленә, сәяси инануларына, дингә мөнәсәбәтенә бәйсез рәвештә, китапханәләрдән файдалана алу хокукына һәм үзенең ихтыяҗлары, кызыксынулары нигезендә китапханәләрне ирекле сайлау хокукына ия.

2. Китапханәләр фондларыннан файдалану тәртибе, күрсәтелә торган төп хезмәтләрнең исемлеге һәм китапханәләр тарафыннан аларны күрсәтү шартлары китапханәләр уставы яисә китапханәләр структур бүлекчәләре булып санала торган оешмаларның эчке норматив актлары, балаларны аларның сәламәтлегенә һәм (яисә) үсешенә зыян китерүче мәгълүматтан саклау турында Россия Федерациясе законнары, дәүләт сере һәм законнар белән саклана торган башка серләр турында Россия Федерациясе законнары һәм Россия Федерациясе халыкларының мәдәни казанышлары сакланышын тәэмин итү турында законнар белән билгеләнә.

3. Китапханәдән файдаланучы конкрет документның китапханәләр фондларында булу-булмавы турында теләсә кайсы китапханәдә түләүсез мәгълүмат алу хокукына ия.

4. Һәркем файдалана алырлык китапханәләрдә гражданнар түбәндәге хокукларга ия:

1) шәхесне таныклый торган документларны күрсәтеп, ә 14 яшькә кадәрге балигъ булмаганнар, законлы вәкилләренең шәхесен таныклый торган документларны күрсәтеп, китапханәләрдән файдаланучы булырга;

2) каталоглар системасы аша һәм китапханәләрдә мәгълүмат алуның башка рәвешләре ярдәмендә китапханәләр фондларының составы турында түләүсез тулы мәгълүмат алырга;

3) мәгълүмат чыганакларын эзләүдә һәм сайлауда түләүсез консультация ярдәме алырга;

4) китапханәләр фондларыннан вакытлыча файдалану өчен теләсә нинди документны түләүсез алып торырга;

5) башка китапханәләрдән китапханәара абонемент буенча документлар яисә аларның күчермәләрен алырга;

6) китапханәдән файдалану кагыйдәләрендә билгеләнә торган башка төрле, шул исәптән түләүле хезмәт күрсәтүләрдән файдаланырга.

5. Китапханәләрдән файдаланучылар дәүләт китапханәләрендә һәм муниципаль китапханәләрдә рус һәм татар телләрендә хезмәт күрсәтелү һәм документлар алу хокукына ия.

6. Китапханәләрдән һәм китапханә хезмәте күрсәтүләрдән инвалидларның файдалана алуы өчен шартлар инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә тәэмин ителә. Сукырлар, начар күрүчеләр махсус дәүләт китапханәләрендә һәм һәркем файдалана алырлык башка китапханәләрдә китапханә хезмәте күрсәтелүгә һәм документларның нөсхәләрен төрле мәгълүмат саклагычларда үзләренә җайлы махсус форматларда алырга хокуклы.

7. Өлкән яшькә җитүләренә һәм физик кимчелекләренә бәйле рәвештә китапханәләргә йөри алмаган китапханәләрдән файдаланучылар һәркем файдалана алырлык китапханәләр фондларыннан документларны тиешле бюджетлар акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин ителә торган стационардан тыш һәм читтән торып хезмәт күрсәтү рәвешендә алырга хокуклы.

8. Китапханәләрдән файдаланучы балалар һәм үсмерләр һәркем файдалана алырлык китапханәләрдә, балалар һәм үсмерләр өчен махсус дәүләт китапханәләрендә, шулай ук мәгариф оешмалары китапханәләрендә әлеге китапханәләрнең уставлары нигезендә китапханә хезмәте күрсәтелүгә хокуклы.

9. Китапханәләрдән файдаланучылар китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрен үтәргә тиеш. Китапханәләрдән файдалану кагыйдәләрен бозган һәм зыян китергән файдаланучылар аны Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә түләргә тиеш.

### 7 статья. **Китапханәләрнең попечительлек (иҗтимагый) советлары**

1. Дәүләт китапханәләрендә һәм муниципаль китапханәләрдә консультатив (киңәшү) органнар хокукында попечительлек (иҗтимагый) советлар төзелергә мөмкин.

2. Попечительлек (иҗтимагый) советлар төзү һәм аларның эшчәнлек тәртибе, шулай ук аларның эшчәнлегендә гражданнарның катнашу тәртибе тиешенчә мәдәният өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы, җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнә.

3. Попечительлек (иҗтимагый) советлар халыкка китапханә хезмәте күрсәтүне камилләштерүгә, китапханәләр эшчәнлеген тәэмин итү өчен бюджеттан тыш финанс чаралары җәлеп итүгә булыша.

8 статья. **Китапханәләр фондлары составына керә торган документларны исәпкә алу, туплау, саклау һәм алардан файдалану**

1. Китапханәләр Федераль закон нигезендә китапханәләр фондлары составына керә торган документларны исәпкә алуны, туплауны, саклауны һәм алардан файдалануны мәдәният өлкәсендә федераль башкарма хакимият органы билгеләгән тәртиптә гамәлгә ашыра.

2. Милли китапханә фондына кертелгән документларны исәпкә алу, туплау, алардан файдалану һәм аларның сакланышын тәэмин итү китапханәләр, архивлар, музейлар тарафыннан Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

3. Китапханәләр үз фондларын туплау чыганакларын мөстәкыйль билгеләргә хокуклы.

4. Китапханәләр фондларын туплау документларның мәҗбүри нөсхәсе системасы нигезендә, сатып алу, язылып алу, алмаштыру, бүләккә алу, иганәләр бирү юлы, шулай ук Россия Федерациясе законнарына каршы килми торган башка ысуллар белән башкарыла.

9 статья. **Татарстан Республикасы Милли китапханәсе**

1. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе – республикада, Россиядә һәм чит илләрдә эшләнгән документларның төп дәүләт китап саклагычы, күпфункцияле китапханә-мәгълүмат оешмасы, мәдәни, аң-белем таратучы, фәнни, библиографик, методик үзәк.

2. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе юридик зат булып тора, аның мөстәкыйль балансы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы раслаган үз уставы була.

3. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең бинасы һәм башка мөлкәте оператив идарә итү хокукында беркетелә. Татарстан Республикасы Милли китапханәсен, аның корылмаларын һәм биналарын да кертеп, хосусыйлаштыру тыела.

4. Татарстан Республикасы Милли китапханәсе фонды республиканың фәнни һәм мәдәни байлыгы булган документларны киләчәк буыннар өчен саклауны тәэмин итә.

5. Татарстан Республикасы Милли китапханәсен бетерү яисә аның профилен үзгәртү тыела, аның фондының бөтенлеге һәм кагылгысызлыгы гарантияләнә.

6. Милли китапханә түбәндәге функцияләрне башкара:

1) илебездә әзерләнгән документларның һәм чит илләрнең фәнни әһәмияткә ия документларының иң тулы җыелмасын барлыкка китерү, саклау һәм файдаланучыларга тәкъдим итү;

2) тулылык һәм мәңге саклыныш принципларында Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә нәшер ителгән туган як һәм татар әдәбияты фондын барлыкка китерү;

3) Татарстан Республикасы турындагы документларның библиографик исәбен алып бару;

4) Татарстан Республикасы иминият китапханә фондын булдыру һәм саклау;

5) Татарстан Республикасы дәүләт китапханәләре эшчәнлегенә фәнни-ысулый җитәкчелек итү;

6) Россия Федерациясе субъектлары китапханәләренә ысулый ярдәм күрсәтү, аларның фондларын туган як турындагы әдәбият һәм татар әдәбияты белән тулыландыруга булышлык итү;

7) әлеге Законда һәм аның нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралган башка функцияләр.

10 статья. **Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе**

1. Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе – Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы, ул Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсеннән файдаланучыларга, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә, рөхсәт ителә торган электрон рәвештәге документлар һәм белешмәләр берлегеннән (алга таба – Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе объектлары) гыйбарәт.

2. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсеннән файдаланучылар булып түбәндәгеләр санала:

1) китапханәләр бинасында Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе объектларыннан, шул исәптән «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә, файдаланучылар;

2) китапханәләрдән файдаланмаучы һәм Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе объектларыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре ярдәмендә файдаланучы физик затлар.

3. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе объектларыннан файдалану мөмкинлеге бирү авторлык һәм уртак хокуклар турында Россия Федерациясе законнары таләпләрен истә тотып гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе объектларыннан файдалану мөмкинлеге бирү тәртибе һәм шартлары, Татарстан Республикасы Милли электрон китапханә объектларын сайлап алу методикасы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсе турында нигезләмә белән билгеләнә.

5. Татарстан Республикасы Милли электрон китапханәсен тулыландыруны координацияләү операторы булып Татарстан Республикасы Милли китапханәсе санала.

11 статья. **Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе**

1. Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе сукырларга һәм начар күрүчеләргә китапханә хезмәте күрсәтү өлкәсендә Татарстан Республикасы территориясендә мәдәни, мәгълүмати-библиографик үзәк булып тора.

2. Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсенең төп функцияләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус мәгълүмат саклагычларда булган документларның китапханә фондын исәпкә алу, туплау һәм саклау, шул исәптән документларның мәҗбүри нөсхәсе системасы нигезендә;

2) сукырларны һәм начар күрүчеләрне махсус форматлардагы рус һәм татар телләрендә әдәбият белән тәэмин итү;

3) китапханәләрдән файдаланучыларга сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус форматлардагы документларны стационар, стационардан тыш һәм читтән торып хезмәт күрсәтү аша бирү.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән функцияләрдән тыш, Сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен республика махсус китапханәсе түбәндәгеләрне башкара:

1) бары тик сукырлар һәм начар күрүчеләр куллану өчен генә булган форматларда рус һәм татар телләрендә китаплар нәшер итү;

2) китапханәләрдән файдаланучыларга күрү буенча чикләүләре булган затлар өчен булган махсус техник чаралардан һәм технологияләрдән файдалану мәсьәләләре буенча консультацияләр бирү;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә башка функцияләр.

12 статья. **Татарстан Республикасының иминият китапханә фонды**

1. Татарстан Республикасында документаль фәнни, мәдәни һәм тарихи мирасны саклап калу һәм тиз арада торгызу максатларында иминият китапханә фондлары төзелә.

2. Татарстан Республикасының иминият китапханә фонды – Татарстан Республикасы халыкларының фәнни, мәдәни һәм тарихи мирасын саклап калу өчен аеруча уникаль һәм әһәмиятле булган документларның, барлыкка килү вакытына, материалына һәм ясалыш техникасына бәйсез рәвештә, классификацияләнгән, системалаштырылган һәм имин саклана торган иминият күчермәләре җыелмасы.

3. Татарстан Республикасының иминият китапханә фондына шулай ук китапханәләрнең аеруча кыйммәтле документлар булган каталоглары кертелә.

4. Татарстан Республикасының иминият китапханә фонды микроформаларда (аналог документлар өчен) яисә электрон саклагычларда, аудиовизуаль чыганакларда, фонодокументларда барлыкка китерелә, документларның төп нөсхәләреннән территориаль аерым саклана һәм китапханә-мәгълүмат хезмәте күрсәтү системасына керми.

5. Татарстан Республикасының иминият китапханә фондын булдыру тәртибе, аны саклау һәм озак вакытлар файдалану шартлары Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Татарстан Республикасының иминият китапханә фонды турында нигезләмәдә билгеләнә.

6. Иминият китапханә фондларын барлыкка китерү мәсьәләсе буенча китапханәләр эшчәнлеген координацияләү Татарстан Республикасы Милли китапханәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

13 статья. **Татарстан Республикасы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» 1998 елның 21 октябрендәге 1818 номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11);

2) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 25 февралендәге 6-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 2 (I өлеш);

3) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2006 елның 24 июлендәге 62-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 7 (I өлеш);

4) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 16 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 5 (I өлеш);

5) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 15 мартындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 3);

6) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 12 июнендәге 53-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2014, № 6 (II өлеш);

7) «Инвалидлар хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 9 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2015, № 10 (I өлеш);

8) «Китапханәләр һәм китапханә эше турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 17 ноябрендәге 83-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 40 (I өлеш);

9) «Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 13 ноябрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 85 (I өлеш).

14 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә, моңа әлеге Законның 10 статьясының 4 өлеше һәм 12 статьясының 5 өлеше керми.
2. Әлеге Законның 10 статьясының 4 өлеше һәм 12 статьясының 5 өлеше рәсми басылып чыккан көненнән соң 180 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2019 ел, 06 август
№ 65-ТРЗ